**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№8100**
**13.12.2021**

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә күпфатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 24 октябрендәге 6345 номерлы карары үз көчен югалтуны тану хакында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак-төзелеш кооперативының күпфатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзалары акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлегенә региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 30 сентябрендәге 938 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Күпфатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 2 октябрендәге 944 номерлы Карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.21, 5.22 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитет карары үз көчен югалткан дип танырга:

1) 2018 елның 12 декабрендә, 2018 елның 21 декабрендә «Челнинские известия» газетасының 90 нчы һәм 93 нче саннарында бастырып чыгарылган «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә күпфатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 24 октябрендәге 6345 номерлы;

2) 2019 елның 11 декабрендә «Челнинские известия» газетасының 91 нче санында бастырып чыгарылган «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге

территориясендә күпфатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 2 декабрендәге 6217 номерлы.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет карамагындагы күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроле һәм күзәтчелеге бүлеге башлыгы Л.М. Кудряшовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов